| | |
|---|---|
| ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 ел 07 ноябрь Петровский Завод авылы №6

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Петровский Завод авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Петровский Завод авылы гражданнары җыенын Петровский Завод авылы мәдәният йорты бинасында 2024 елның 22 ноябренә: 10 сәгать 00 минутка хэм 14 сэгать 00 минутка.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкән кешеләр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылардан кала, Петровский Завод авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1: Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Петровский Завод торак пунктында урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру):

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Петровский Завод торак

пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча машина йөртүченең эшләренә һәм хезмәтләренә түләү), (Петровский Завод торак пунктының Аръяк һәм Таулы урамнары юлын ремонтлау (таш белән капланган чокырлы ремонт, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча хезмәтләргә түләү), Декабристлар урамында асфальт түшәлгән юлда чокырлар ремонтлау (асфальт валчыкларын ташу һәм салу, махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, грейдерлау);

3. Петровский Завод торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (территорияне чабу һәм коры агачларны кисү, триммер өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү; зират территориясен саклау өчен материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү; зиратка кадәр керү юлын төзү - вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Петровский Завод торак пункт территориясендә улэн чабу, корыган агачларны кисү (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү, территорияне чабу өчен триммерлар сатып алу;

5. Петровский Завод торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү краннары сатып алу, урнаштыру һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, янгын сүндерү җиһазләре, янгын сүндерү бочка арбасы өчен тәгәрмәчләр сатып алу)?

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә игълан итәргә.

Петровский Завод
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Нуртдинов